**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның «16» июленнән № 11-73

2026 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2027 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.И.Бутинаның 2026 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2027 елга бурычлар мәсьәләсе буенча мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2027 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар челтәрен киңәйтүне һәм районның социаль проблемаларын хәл итүдә аларның ролен арттыруны тәэмин итәргә;

җирле үзидарә органнары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә;

коммерциячел булмаган оешма вәкилләре өчен укыту чараларын һәм семинарлар уздыруны тәэмин итәргә;

муниципаль берәмлек халкына коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләр өлкәсен үстерү өчен шартлар тудырырга;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларны грантлар алуга конкурсларга җәлеп итү буенча системалы эш оештырырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдим итәргә:

региональ һәм федераль ярдәм программаларында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның катнашуын активлаштырырга;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегендә ачыклыкны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы — Е.А. Тарнавский